**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «10» декабреннән № 305

Аерым категория гражданнарына «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең спорт объектларына ташламалы йөрү билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле һәм керем китерә торган башка хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 40-325 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан түләүле чаралар оештырганда кимендә атнага бер тапкыр бушлай керүне кулланучыларның түбәндәге категорияләренә билгеләргә (раслый торган документлар биргәндә):

күп балалы гаиләләрдәге балаларга эш көннәрендә, бәйрәм көннәреннән һәм каникул вакытларыннан тыш, 18.00 сәгатькә кадәр;

«риск төркеме» категориясендәге балаларга һәм яшүсмерләргә (төркем белән булганда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия секретаре белән алдан килештерелгән гариза булганда, эш көннәрендә, бәйрәм көннәре һәм каникул вакытларыннан тыш, 18.00 сәгатькә кадәр);

ятим балаларга эш көннәрендә, бәйрәм көннәреннән һәм каникул вакытларыннан тыш, 18.00 сәгатькә кадәр;

инвалид балаларга;

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан түләүле чаралар оештырганда, түбәндәге кулланучылар категорияләренә (раслаучы документлар биргәндә) хезмәтләр бәясенең 50 %ы рәвешендә ташламалар билгеләргә: инвалидларга һәм пенсионерларга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru/, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов